# КАРАР

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге составына керүче Урсай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**22.12.2021** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 22 нче декаберендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде:«Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең Урсайавылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2022 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (агач, куаклар кисү)
- зиратны төзекләндерү (агач, куаклар кисү);
- чишмәне төзекләндерү (агач, куаклар кисү), чишмә территориясен киртәләү;
- чишмәгә юл салу;
- мәгълүмат стендын сатып алу һәм урнаштыру.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 220 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 114 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 100 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 14 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең Урсай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Урсай җирлегенең Урсай авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2022 елда үзара

салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (агач, куаклар кисү)
- зиратны төзекләндерү (агач, куаклар кисү);
- чишмәне төзекләндерү (агач, куаклар кисү), чишмә территориясен киртәләү;
- чишмәгә юл салу;
- мәгълүмат стендын сатып алу һәм урнаштыру соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре»бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Урсай
авыл җирлеге башлыгы ________________ Гатина Н.А.